## Иманга юл

# Изгелектә ярышыйк

Шәгъбан - Пәйгамбәребез ае, аның шәфәгатен безгә насыйп итә торган ай. Бу айда тоткан уразаларның, кылган изге гамәлләрнең савабын Аллаһ Тәгалә күп мәртәбә арттырыр. Шәгъбан аенда бер изге кичә бар - Бәраәт кичәсе, бу айның 15нче кичәсе. Бу - гөнаһлардан котылу, бәхет һәм иминлек, төрле уңышлар, изгелекләр иңә торган кич. Шушы кичне Аллаһ Тәгалә һәрбер кешенең бер еллык язмышын билгели. Аллаһ Тәгалә Расүлебез галәйһис-сәлам Җәбраил фәрештә аркылы белгерткән: "Бу кичәдә өч йөз рәхмәт ишеге ачылыр. Аллаһ Тәгалә ярлыкар һәр мөселман бәндәне, ун төркемне ярлыкамас: сихерчене; күрәзәчәлек кылучыны, бер мөселман белән үпкәләшеп, сөйләшмичә йөрүчене, тәкәбберләрне, исерткеч эчүчене, зина кылучыны, риба алучыны, ата-анасын рәнҗетүчене, нахакка кеше үтерүчене, фитнә чыгаручыларны. Әгәр ихлас күңел белән тәүбә кылып, бу эшләрен ташласалар, аларны ярлыкар" - Шәгъбан аена керергә. Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам әйтүенчә, Шәгъбан аеның исеме гарәпчә "тәшәгабә" сүзеннән чыккан, ул "тарала" дигән мәгънәне белдерә, бу айда изгелек дөньяга тарала. Бу айны хөрмәтләп, изгелекләрен арттыручыларның Аллаһ Тәгалә гөнаһларын ярлыкап, киләсе елда бәла-казалардан саклаячак. Шәгъбан ае Аллаһ безгә насыйп итте өч изге айның икенчесенә.

Шуңа күрә, кадерле якташларым, бу кичәдә, бу айда гөнаһларыбызга тәүбә кылыйк, хәрам эшләрдән ерак булыйк, Аллаһ кушканнарын үтик, изгелекләребезне арттырыйк, нәфел уразалар тотыйк. Кайсыларыбыз намазга басмаган булсак, бу изге айларда шул туры юлга күнегеп китик, һәр изгелекләребезне кеше мактасын, кеше күрсен дип, риядан түгел, Аллаһның ризалыгы өчен эшлик!

**Халит хәзрәт ВАЛЕМЕЕВ**
**язмасыннан.**

# МАКСАТ — ГАФЫЙЛЬ БУЛМЫЙК!

**Сәүдахан хәзрәт ГАЙНЕТДИНОВ**

***Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә безгә-үзенең колларына - тәкъдим иткән җәннәтләренә керү өчен, кушканнарын үтәп вә тыйганнарыннан тыелып, Ислам кануннары вә пәйгамбәребез сөннәте буенча яшәргә боерган. Һәм дә гыйбадәт вә тәүбә-истигъфар кылып, савап эстәү, гөнаһлардан арыну, Үзен даими зекер итеп, хак мөэмин-мөселманнар юлына басу өчен бөтен мөмкинлекләрне дә булдырган.***

Мисал өчен иң элек атнаның иң хәерле көне саналган җомга көненә тукталыйк. Бу көнне Аллаһы Тәгалә гыйбадәтләрне, аерым алганда, җомга намазын чын күңелдән вә җиренә җиткереп башкаручылардан 600000 кешегә үзенең җәннәтенә керергә юллама бирер икән. Шунлыктан, җомга намазын вә башка гыйбадәтләрне: "Әлеге бәндәләрнең берсе мин булсам иде!" - дип кылырга, шул теләктә булырга кирәк. Тагын шунысы: җомга намазы ике гаеттән дә зуррак. Ул мескеннәрнең хаҗы санала. Әмма күпләр җомга намазының әҗер савабы бик зур булуын белми. Белсәләр, мәчеткә үрмәләп булса да барырлар иде, дигән пәйгамбәребез. Җомга көнне, бәлки, намаз вакытындадыр, шундый бер сәгать бар, шул сәгатьтә теләгән теләкне Раббебез кабул итмичә һич калдырмас ди. Шуңа күрә әлеге сәгатьнең кайян булачагын белмәстән, җомга көн, кояш баеганчыга чаклы, зекердә булырга, Раббебезны олылап, яхшы гамәлләр генә кылырга тиешлебез. Чөнки уйламыйча әйткән һәр начар сүзебез, яман гадәтләребез, начар теләкләребез шушы сәгатьтә үзебезгә афәт китерүе, зыян салуы бар.

Инде менә изге айларны искә алыйк. Аларның беренчесе - Рәҗәб - Аллаһ ае. Мөселманнар вә динебез тарихына бәйле әһәмиятле вакыйгаларга бик бай. Әйтик, бу айда пәйгамбәребезнең әти-әнисе кавышкан. 27нче кичәсендә пәйгамбәребез күккә ашкан. Раббебез белән очрашкан. Шушы көнне безгә 5 вакыт намаз фарыз булган.

Бу айда Аллаһыдан гөнаһларыбызны ярлыкауны сорау, нәфел уразасы тоту, гыйбадәтләребезне көчәйтү, туган-тумачалар, күршеләр белән элемтәне ныгыту зур савап. Пәйгамбәребез әйтүенчә, Рәҗәб аеның беренче көнендә ураза тотсаң - 3, ә икенче көнендә тотсаң - 2, өченче көнендә тотсаң - 1 еллык гөнаһыларың ярлыканыр икән.

Инде кемдер, хаталанып, бу кадәрле вакытны гафыйл уздырган икән, Шәгъбан вә Рамазан айларында уяу булырга кирәк. Чөнки бу айларда тоткан ураза шулай ук күп кенә гөнаһларга каффәрәт булыр, ди.

Икенче изге ай - Шәгъбан - пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм ае. Кыямәт көнендә шәфәгатен алу өчен без, аның сөннәтләрен үтәү, гыйбадәтләребезне арттыру, нәфел уразасы тоту, сәдакалар бирү белән бергә, пәйгамбәребезгә карата булган олы мөхәббәт һәм хөрмәтебезне гыйбадәтләребездә ачык белдерергә тиешбез.

Чираттагы өченче изге ай - Рамазан - безнең, ягъни, пәйгамбәребез өммәте ае. Аңа әҙерлек Рәҗәб аенда ук башланса, Шәгъбан аенда ул тагын да көчәя төшә. Рамазан ае безгә, күңелебезне сафлап, Аллаһы Тәгалә тарафыннан һидәят өчен туры юлга күнәр өчен зур бүләк итеп бирелгән.

Бу айда Раббебез кешеләргә нәкъ менә туры юлны күрсәтүче һәм һидәятне ачык бәян кылучы Коръәнне индергән. Башка айларда аннан, тырышып-тырмашып, бер аять яисә бер хәреф өйрәнсәк, бер хәрефкә 10 савап тисә, әлеге изге айларның баштагы икесендә - 1000 әр, ә инде Рамазан аенда хәтта 7000 гә кадәр савап язылыр икән.

Образлы итеп әйткәндә, "Рәҗәб - чәчү, Шәгъбан - су сибү, Рамазан - җыю" айлары. Белгәнебезчә, яхшы орлык чәчсәң, Аллаһ рәхмәте белән, вакытында яңгыр яуса, көзен мул уңыш җыеп алабыз. Шуның шикелле, изге гамәлләребезне чын күңелдән кылсак, аларны яхшы эшләр белән ныгытсак, иншалла, Аллаһ үзенең рәхмәтенә алмыйча калмас. Бу айларда без, Раббебез аларны безләргә мөбәрәк кылып, күбрәк тәүбә итәргә, гыйбадәтләребезне көчәйтергә, ятимнәргә, мескеннәргә вә авыруларга сәдакалар биреп, аларны сөендерергә тиешбез.

Әлбәттә, бүләкләр биреп, хәлләрен белеп, үз гаиләбездәгеләрне, дусларны, күршеләрне сөендерү дә зур саваплы. Әлеге изге айларда бу эшләргә һәр мөселман хирыс булырга тиеш. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен өмет итеп, һәркайсыбыз яман эшләребезне киметик, изге гамәлләрне күбрәк кылыйк, җәмәгать! Шунысы да бар: рәҗәб ае Аллаһы Тәгалә сугыш һәм талашларны тыйган 4 айның да (Рәҗәб, Зөлкагдә, Мөхәррәм) иң беренчесе. Раббебез әйтә: "Рәҗәб аенда мин ачуымны бикләп куярмын, рәхмәтем яңгыр шикелле явар", - ди. Шуңа күрә гафыйл булмыйк, әлеге изге айларны һәм алардагы Рәгаиб, Мигъраҗ, Бәраәт, Кадер кичәләрен һәммәбез дә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешик дисәк, чыннан да, изге санап вә Раббебез кушканча кадерләп, әйбәт итеп үткәрергә тырышыйк. Шушы саваплы айларда Хак Тәгалә каршында чиста, пакъ булып, гөнаһларыбыздан арынып, изге гамәлләр белән танылсак, әлбәттә, иминлек вә ахирәт-дөнья бәхете белән бүләкләнербез - Аллаһы Тәгалә кыямәт көнендә безләрне, сират күпере аша ансат кына-яшен тизлегендә уздырып, үзенең җәннәтләре белән сөендерер, шәт.

## Өфөлә намаҙ вақыты

### Шәғбан-Рамаҙан 2012 миләди йыл 1433 һижри йыл.

| Шәғбан, Рамаҙан | Аҙна көндәре | Июнь, Июль | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 | Дүшәмбе | 17 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 9 | Шишәмбе | 18 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 10 | Шаршамбы | 19 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 11 | Кесе йома | 20 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 12 | Йома | 21 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 13 | Шәмбе | 22 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 14 | Йәкшәмбе | 23 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 15 | Дүшәмбе | 24 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 16 | Шишәмбе | 25 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 17 | Шаршамбы | 26 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 18 | Кесе йома | 27 | 4.13 | 5.43 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 19 | Йома | 28 | 4.13 | 5.43 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 20 | Шәмбе | 29 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 21 | Йәкшәмбе | 30 | 4.15 | 5.45 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 22 | Дүшәмбе | 1 | 4.16 | 5.46 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 23 | Шишәмбе | 2 | 4.16 | 5.46 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 24 | Шаршамбы | 3 | 4.17 | 5.47 | 14.30 | 21.22 | 22.52 | 00.22 |
| 25 | Кесе йома | 4 | 4.18 | 5.48 | 14.30 | 21.22 | 22.52 | 00.22 |
| 26 | Йома | 5 | 4.19 | 5.49 | 14.30 | 21.21 | 22.51 | 00.21 |
| 27 | Шәмбе | 6 | 4.20 | 5.50 | 14.30 | 21.21 | 22.51 | 00.21 |
| 28 | Йәкшәмбе | 7 | 4.21 | 5.51 | 14.30 | 21.20 | 22.50 | 00.20 |
| 29 | Дүшәмбе | 8 | 4.22 | 5.52 | 14.30 | 21.19 | 22.49 | 00.19 |
| 1 | Шишәмбе | 9 | 3.53 | 4.23 | 14.30 | 21.18 | 22.48 | 00.18 |
| 2 | Шаршамбы | 10 | 3.54 | 4.24 | 14.30 | 21.17 | 22.47 | 00.17 |
| 3 | Кесе йома | 11 | 3.56 | 4.26 | 14.30 | 21.16 | 22.46 | 00.16 |
| 4 | Йома | 12 | 3.57 | 4.27 | 14.30 | 21.15 | 22.45 | 00.15 |
| 5 | Шәмбе | 13 | 3.58 | 4.28 | 14.30 | 21.14 | 22.44 | 00.14 |
| 6 | Йәкшәмбе | 14 | 3.59 | 4.29 | 14.30 | 21.13 | 22.43 | 00.13 |
| 7 | Дүшәмбе | 15 | 4.01 | 4.31 | 14.30 | 21.12 | 22.42 | 00.12 |

## Безгә язалар

# ГАЗЕТАНЫ КӨТЕП АЛАБЫЗ

Хөрмәтле "Рисәләт" гәзите хезмәткәрләре! Мин Борай районы Иске Бикмәт мәчете мөселманнары исеменнән үтенечебезне язып җибәрмәкче булдым. Мәчетебез 2004 елның уразага кергән көнендә ачылды. Анда Нурмөхәммәт хәзрәт безгә бик матур вәгазь сөйләде, бергәләп намаз укыдык. Уфа мәчетләренә шул елларда экскурсиягә бардык. Аның белән бергәләп Дикия нәзәратендә чәй эчеп, намаз укыдык. Хәзрәтнең һәр сүзе хәтергә сеңеп калды, үтемле булды. Мәчетебезне һәр көн ачабыз, җомгаларыбыз үтә, вәгазьләр сөйлибез, "Корьән"не елга бер тапкыр укып чыгабыз. "Рисәләт", "Ислам нуры", "Вакыт" газеталарын алдырабыз. Аларны вәгазьләребездә файдаланабыз. Республикабызда яңалыклар (дин өлкәсендә) белән танышабыз. Тик авылыбызда хәзер картлар, карчыклар гына яши дияргә була. Шулар ук мәчеткә йөриләр, килә алмаганнар белән Корьән мәҗлесләрендә очрашабыз. Күбесе кыйммәт хакка "Атна", "Өмет" газеталарын алдыралар, чөнки намаз вакытлары чыга, шуңа алдырабыз, диләр. Безнең тәкъдим: "Рисәләт", "Послание" дип ике газета итеп чыгарсагыз иде. Хакы да шул ук булсын, без ризабыз. Мәдрәсәләргә керем дә күберәк булыр, сававыбыз да булыр иде. Русча белгәннәр үзенекен, башкортча, татарчасын милли телебездә укыр идек. Мәҗлесләрдә язылуны оештырыр идек.

Васил хәзрәт Тимергалиевнын, Морат хәзрәт Лукманның "Иман" тапшыруларын көтеп кенә торабыз. Ашкадарда "Фатыйха" тапшыруының тукталуына үкенеч белдерәбез. Бик яратып тыңлый идек. Фәкать дин генә дөрес тәрбия бирә, кешене бәхетле итә. Безнең тәкъдимнәрне кабул итсәгез иде.

***Мәчеткә йөрүче мөселман кардәшләрем исеменнән, Наилә абыстай Шайхова, Борай районы, Иске Бикмәт авылы.***

## Каурый каләм

### БЕР ХОДАЙДАН...

*Бер ходайдан, мәхәббәт сорама син.*
*Бер ходайдан, сора ярдәмен.*
*Ярдәменнән безне ташламасын*
*Барыбызга да шуны әйтәмен.*

*Бер ходайдан, бәхет сорама син.*
*Бәхет өләшми, ул күкләрдән.*
*Иман нуры, качып бара бездән,*
*Качкан инде, ул бик күпләрдән.*

*Бер ходайдан, байлык сорама син*
*Байлык бит ул, була бер айлык.*
*Яшә җирдә үз байлыгың белән,*
*Шул вакытта килер зур шатлык.*

*Бер ходайдан сора, исәнлегең...*
*Исәнлек ул гомер байлыгы.*
*Исән кеше аңлар яшәү ямен,*
*Исән кеше генә, булмас кайгылы.*

*Бер ходайдан сора, ярлыкавын...*
*Бу дөньяда без бит гөнаһлы.*
*Кичер, ходам, адәм балаларын,*
*Адым саен ясыйбыз гөнаһны...*

**Лилия СӘХӘБИЕВА.**